**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
20 нче май 2025 ел

**РЕШЕНИЕ**
№45-10

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының «Актаныш муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 14 декабрендәге 13-07 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 540-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының «Актаныш муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 14 декабрендәге 13-07 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. 4.7.1 пунктына** түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

- «Инспекция визиты үзара дистанцион аралашу чараларыннан, шул исәптән видео-конференц-элемтә, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып үткәрелергә тиеш.

**- 2** абзацны 3 абзац дип санарга

**1.2. 4.6.1 пунктындагы 2 абзацны** түбәндәге эчтәлекле абзац белән алмаштырырга:

«Күчмә тикшерү үзара дистанцион аралашу чараларын, шул исәптән видео-конференц-элемтә, шулай ук «Инспектор» мобиль кушымтасын кулланып үткәрелергә мөмкин.»

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Актаныш муниципаль районы
Советы рәисе Л.Р.Зарипов